Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авыл Советы
КАРАРЫ

02 августа 2021 ел № 23

Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 90 номерлы « Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаш авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә

Ямаш Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 90 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаш авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында»гы карарына (Ямаш авыл Советының 2014 елның 19 декабрендәге 130, 2015 елның 05 маендагы 146, 2020 елның 12 маендагы 104, 2020 елның 18 декабрендәге 5 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац естәргә:

« авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә карата даими сроксыз файдалану хокукында яки милек хокукында булган дини оешмалар.»

1.2. алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга.

2.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктындагы беренче абзацы рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ямаш авыл җирлеге башлыгы Е.С. Ларин